| | | |
|---|---|---|
| ИНСПЕКЦИЯ ГОСУДАРСТВЕННОГО СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ |

ПРИКАЗ　　　　　　　　　　　　　　　　БОЕРЫК

__02.03.2023___　　　Казан шәһәре　　　№ _18__

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыру, нал белән акча һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс коралларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында

«Затларның аерым категорияләренә Россия Федерациясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачуны (акча салуны) һәм булдыруны, нал белән акчалар һәм кыйммәтләр саклауны, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалануны тыю турында» 2013 елның 7 маендагы 79-ФЗ номерлы федераль законның 2 статьясындагы 1 өлешенең 1 пунктының «и» пунктчасы, «Коррупциягә каршы торуның кайбер мәсьәләләре турында» Россия Федерациясе Президентының 2015 елның 8 мартындагы 120 номерлы Указының 2 пункты, «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре өчен вазыйфа биләгәндә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар ачу (акча салу) һәм булдыру, нал белән акчалар һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс инструментларына ия булу һәм (яки) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген раслау турында» 2015 елның 8 июнендәге ПУ-542 номерлы Татарстан Республикасы Указы нигезендә

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Кушымтада бирелә торган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыру, нал белән акча һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс

коралларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеген расларга.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Хокукый эш һәм өлешле төзелешне тикшерүдә тоту идарәсенең хокук бүлегенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

Башлык В.А. Кудряшов

Татарстан Республикасы
Дәүләт төзелеш күзәтчелеге
инспекциясенең
_02.03.2023_№_18_
боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә вазыйфа биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләренә Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачу һәм булдыру, нал белән акча һәм кыйммәтләр саклау, чит ил финанс коралларына ия булу һәм (яисә) алардан файдалану тыела торган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясендә Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестры турында» 2006 елның 18 гыйнварындагы ПУ-9 номерлы Указы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары реестрында иң югары вазыйфалар төркеменә кертелгән Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары:

Татарстан Республикасының Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе җитәкчесе.